СОВЕТ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.03.2025 г. Заинск № 384

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 42 статьясына үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 12 декабрендәге 89-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 19 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 12 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 12 декабрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының 14.11.2014 № 414, 04.03.2015 №438, 21.05.2015 № 455, 16.10.2015 №14, 18.12.2015 № 35, 26.08.2016 № 136, 15.12.2016 № 186, 29.03.2017 № 205, 05.07.2017 № 220, 07.09.2017 № 232, 10.09.2018 № 332, 22.04.2019 № 390, 30.09.2019 № 438, 11.03.2020 № 485, 03.06.2020 № 530, 11.11.2020 № 11, 03.03.2021 № 35, 07.10.2021 № 172, 04.03.2022 № 206, 27.01.2023 № 270,

10.08.2023 № 287, 30.11.2023 № 301, 18.04.2024 № 330, 2024 елның 18 октябрендәге 355 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 20 статьяның 3 өлешендәге 5 пунктына «һәм квалификация турында» сүзләрен өстәргә.;

1.2. 29 статьяда:

а) 10 өлешнең 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

б) 11 өлештә «1-3 пунктларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3. 42 статьяның 4 өлешендә «2025 елның 1 гыйнварыннан» сүзләрен «2028 елның 1 гыйнварыннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU), һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары П. С. Уразайкинга йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**